Бүгенге санда:



Язгы чакырылышта 99 Нурлат егете армиягә китте. 2 бит



1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 3 июль 2015 ел

№ 48 (10577)

**4 июльгә һава торышы:** аязучан болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көнбатыштан 3-4 м/с; температура көндез +15°С, төнлә +14°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### АМБРОЗИЯГӘ КАРШЫ КӨРӘШӘЛӘР

Россельхознадзорның Нурлат районара бүлеге авыл җирлекләрендә амброзия һәм кыр повиликасы кебек карантинлы чүп үләннәрен ачыклауга мониторинг үткәрү белән мәшгуль. Яңа Иглай, Иске Чаллы, Мамык, Төрнәс, Елаур, Фома, Чуваш Тимерлеге авыл җирлекләрендә үткәрелгән тикшерүләр әлеге җирлекләр территорияләрендә карантинлы чүп үләннәре булуын күрсәткән. Хәзер бу җирлекләрдә аларны бетерү өчен көрәш бара.

### УРАЗА БӘЙРӘМЕНДӘ ӨЧ КӨН ЯЛ

Быел Ураза гаете 17 июль көнне билгеләп үтелә. Изге бәйрәм җомга көненә туры килгәнлектән, биш көнлек эш атнасы графигы нигезендә эшләүчеләр, 17, 18, 19 июльдә ял итәчәк. Корбан бәйрәме исә 24 сентябрьгә туры килә.

### ДЕПУТАТ КАБУЛ ИТӘ

7 июльдә ТР Дәүсоветы депутаты Илгиз Мисбах улы Салихов Нурлат районындагы сайлаучылары өчен чираттагы кабул итү уздыра. Кабул итү көндезге 2дә Нурлат шәһәре, Совет ур., 100 адресы буенча узачак.

# Рөстәм Миннеханов президент праймеризында җиңде



Максим Платонов фотосы

**27 июньдә Казанның Теннис академиясендә Татарстан Президенты вазифасына партия эчендә алдан тавыш бирүнең тәгәлләү этабы узды.**

Беренче тапкыр илебездә партия праймеризын җәмәгатьчелек вәкилләре уздырды. Тавышларны санау нәтиҗәләре буенча, сайлаучыларның 95 проценты Татарстан лидеры Рөстәм Миннеханов өчен тавыш бирде.

**Тулырак материалны “Атна вакыйгалары”ннан укыгыз.**

АКТУАЛЬ

# Июль сюрпризларын әзерләде

**2015 елның экваторын уздык. Ә июльдән безнениләр көтәчәк? Сезнең игътибарга аларның кайберләре турында мәгълүмати дайджест тәкъдим итәбез.**

ТРның тарифлар буенча Дәүләт комитеты мәгълүматларыннан күренгәнчә, нурлатлыларга газның кубометры 5 сум 16 тиенгә, бер ставкалы тариф буенча электр энергиясенең киловатты 3 сум 20 тиенгә, суның куб. метры 30 сум 38 тиенгә төшәчәк.

Законга яңа төзәтмәләр кертү белән кулланучыларның хокуклары да киңәйде. Хәзер сыйфатсыз товарны кайтарганда, сатып алучы сатучыдан товарның бәясен генә түгел, ә заем белән бәйле барлык югалтуларны да каплавын таләп итә ала. Мисал өчен, процентлар өчен акча кайтару. Моннан тыш, уйламыйча алынган кредиттан баш тартырга мөмкин. 14 көн дәвамында максатчан булмаган кулланучы заемыннан, ә бер ай эчендә максатчаныннан баш тартырга була. Өстәвенә, просрочка өчен пеня күләмен еллык 20 процентка чикләделәр (кредит суммасына процентлар яки һәр көн просрочка өчен бурыч суммасыннан 0,1 процент исәпләгәндә).

Салым инспекциясеннән әйтүләренчә, июль башыннан физик затларның кертемнәре һәм банк карталары салым органнары контролендә булачак икән. Хәзер банклар салым службасына халыкның кертемнәр ачу-ябуы, реквизитларның үзгәрүе турында хәбәр итеп торырга тиешләр. Моңа кадәр банклар салым службасына бары тик юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең счетлар ачулары турындагы мәгълүматларны гына ирештерәләр иде. Моннан тыш, бер генә гражданин һәм теләсә нинди компания дә блокировкаланган счеты була торып, бернинди яңа счет та яки банк картасы да ачтыра алмый.

1 июльдән автомобиль белән исерек көе идарә иткән өчен җинаять җаваплылыгы кертелә. Моның өчен ике елга кадәр irектән мәхрүм ителү куркынычы, 200-300 мең сум штраф, 480 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр һәм ике елга кадәр мәҗбүри хезмәт яный.

1 июльдән барлык җәяүлеләр дә торак пунктлардан читтә тәүлекнең караңгы вакытында яктылык сирпүче элементлары булган киемнәрдән йөрергә тиеш. Балаларны исә чыгарылган елы 10 елдан да артмаган автобусларда гына йөртү рөхсәт ителәчәк. Иминият компанияләре 1 июльдән ОСАГО полисларын электрон рәвештә сата башлады. Электрон полисны сатып алу схемасы гади. Гражданин иминият компаниясе сайтына керә, күрсәтелгән формада гариза яза, барлык тиешле мәгълүматларны да кертә. Мәгълүматларны тикшергәннән соң, килешү теркәлә, аңа номер сугыла. Клиентка счет бирелә, ул тиешле акчасын түли һәм үз полисын электрон рәвештә ала.

Валентина ВАФИНА әзерләде.

### ВАКЫТЫННАН АЛДА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

**1 июльдән район газетасына 2016 елның I яртыеллыгына 2015 елның II яртыеллыгы бәяләреннән язылу башлана. “Дуслык” белән элеккеге бәяләрдән аралашуыгызны озайтырга ашыгыгыз!**

МТС ты знаешь, что можешь!

СОЗДАЕМ КОМАНДУ ЛИДЕРОВ! г. Нурлат

ВЫ ПОЛУЧИТЕ:
- Стабильную з/п
- График работы 5/2
- Бесплатное обучение
- Быстрый карьерный рост
- Незабываемые корпоративные мероприятия

Запишись на собеседование:
8 800 250 60 50
Сайт rabota.mts.ru

Реклама

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

# Яңгырны "заказ белән" яудыралар




ЕЛЕНА ЛОГИНОВА БЕЛӘН ЮРИЙ ИВАНОВ СУГАРУ СИСТЕМАСЫН КӨЙЛИЛӘР

**Коры көннәр районның күп кенә кырларына зыян салса да, "Сөләйманов Ә.И" КФХсының 300ләп гектарлы бәрәңге басуына әлләни куркыныч тудырмады. Чөнки биредә инде ничә еллар рәттән бәрәңгене сугарулы система буенча үстерәләр.**

"Сөләйманов Ә.И" крестьян-фермерлык хуҗалыгы – районда мондый системадан файдаланучы бердәнбер авыл хуҗалыгы предприятиесе. Соңгы берничә елда коры һава торышы шартларында биредә бәрәңгене башкача үстерүне күз алдына да китерә алмыйлар. Чөнки яңгырлар бу культура өчен дым бик кирәк вакытта – нәкъ менә май, июнь айларында яумыйча тилмертә бит.

Әнә, сишәмбе көнне иртән бөтен тирә-як басуларда җирләр корылыктан тилмергән бер вакытта Пушкино поселогы янәшәсендәге бәрәңге басуындагы су сибү агрегатлары тирәсендәге бәрәңге яфракларыннан су тамчылары тамып тора иде. Су сибү операторы Елена Логинова да шунда гына. Басуга урнаштырылган киң алымлы су сибү агрегатларының көйле эшләп торуы өчен ул һәм Андрей Убамзаров җаваплы.

– Һәр өч сәгать саен солярка салып торырга кирәк, – ди Елена. – Су сибүне көндезге 3тә башлап, төнге 11гә кадәр дәвам итәбез, аннан төнге 3тән иртәнге 10га кадәр.

Агрегатның "канаты" 500ләп метр озынлыкта. Елена әйтүенчә, ул үз күчәре тирәсендә 3 көнгә бер әйләнеш ясый һәм 64 гектарлап мәйданны сугарырга өлгерә. Бу басуда исә шундый өч агрегат урнаштырылган.

Ә сугару системасының буадагы насосларының төзеклеген Юрий Иванов кайгыртып тора. Сөләймановлылар узган ел көздән биредә буаны төзекләндереп калдырган булганнар, шуңа да елгада су кош-кортларга да, коенучыларга да, бәрәңгегә сибәргә дә җитәрлек. Хуҗалыкның башка су сибү җайланмалары исә Фома һәм Биккол авыллары буаларында урнаштырылган, хуҗалыкта аларының төзеклеген дә кайгыртып торалар.

Әлбәттә, хуҗалыкта бәрәңгедән ел саен яхшы уңыш алуларының сере исә әлеге культураны игүдә барлык технологик таләпләрне истә тотуларына да бәйле. Әнә, быел бәрәңгенең сортын яңартып, 60 тонна "Ред Леди" дигән I репродукцияле орлык алып кайтып утырттылар. Җәй дәвамына да биредә үсемлекләрне чүп үләннәреннән, корткычлардан, авырулардан саклау буенча эшләр туктalып тормый. Әлбәттә инде, су сибеп үстерүләре дә файда бирә. Соңгы араларда республикада да сугару системасын үстерүгә зур игътибар бирелә. Күптән түгел республикада шаулап узган Халыкара кыр көннәрендә республика лидеры Рөстәм Миннеханов та мелиорация системасын корылыкка каршы торуда һәм авыл хуҗалыгы производствосын тотрыклы итүдә үтемле чара дип атады. ТР Министрлар Кабинетының "2012–2014 елларда гидротехник корылмаларны торгызу буенча мелиорация эшләре" озак вакытлы программасын 2017 елга кадәр озайтулары да шул максаттан. Гомумән, быел төрле программалар буеча республикада 172 мелиорация объектында төзелеш эшләре бара, тагын 3 меңләп гектарда сугарулы мәйдан булдыру планлаштырыла, республиканың үзендә үк сугару системалары җитештерүче завод төзелеше күздә тотыла. Әмма, нишләптер, Нурлат хуҗалыкларының гына бу юнәлештә әлләни активлык күрсәтүләре сизелми. Сөләймановлылар кебек алга карап заманча фикер йөртүчеләр күбрәк булса, игенчеләр өчен корылык куркынычы да азрак булыр иде үзе.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

ХӘБӘРЛӘР

### ЮЛЧЫЛАР ЯРДӘМ КҮРСӘТӘ

"Татнефтедор"ның Нурлат автоюллар идарәсе елдагыча, быел да "Башаккай" балалар бакчасына, шәһәрнең 4нче мәктәбенә һәм гимназиягә ремонт чорында иганәчелек ярдәме күрсәтә. "Башаккай"га акчалата ярдәм, мәктәпләргә–буяулар бик тә урынлы булышлык булачак.

### ИНТЕРНАТ КЫШНЫ КАЙГЫРТА

150 банка кыяр кышкыга әзер, һәм бу сан көн саен арта тора. Нурлат картлар һәм инвалидлар йорты үз теплицаларында үстергән яшелчәләрдән әнә шулай кышкыга запасны ел да әзерләп калдыра. Запас быел аерата мулдан булырга охшый, чөнки май урталарыннан табынга чыга башлаган кыяр уңышы әле дә кимергә күренми. Тиздән помидорларны да күпләп маринадларга керешәчәкләр, чөнки өлкәннәр рационына шулай ук байтактан үз помидорлары өстәлгән.

Сәкинә **НУРУЛЛИНА**

### ХЕЗМӘТЛӘРЕ ХӨРМӘТЛӘНДЕ

Күптән түгел суд приставларының Нурлат район бүлеге вәкилләрен бүләкләделәр. Шул рәвешле, күпьеллык һәм намуслы хезмәте өчен бүлек начальнигы-өлкән суд приставы Александр Катковка, әйдәп баручы белгеч-эксперт (дознаватель) Наталья Убейкинага һәм әйдәп баручы белгеч-депозит буенча эксперт Эльвира Низаметдиновага Россия ФССПсының III дәрәҗә "Хезмәт өчен" медале тапшырылды.

Валентина **ВАФИНА**

ҺӨНӘРИ БӘЙРӘМ

# Юлларда ял юк

**Бүген ЮХИДИ хезмәткәрләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр.**

Безнең һәркайсыбызга машина йөртүче, пассажир яки җәяүле ролендә ЮХИДИ инспекторы белән очрашырга туры килмичә калмагандыр. Юл инспекторларының хезмәте кыен да, куркыныч та. Ватык машиналар, күз яшьләре, җәрәхәтләнгән кешеләр, кайвакыт мәетләр дә... Кемнедер юатасы, кайберенә ярдәм итәсе, кем дөрес, кайсы гаепләне ачыклыйсы...

Көн саен район юлларында ике сменада 2 экипаж кизү тора. Кичке сәгать 7ләр тирәсе. Патруль машиналары ЮХИДИ бинасы янында, ә инспекторлар киңәшмәдә. Кичке смена бик сирәк очракта тыныч була, диләр инспекторлар. ДПС инспекторы Илназ Җиһаншин пропаганда инспекторы Ринат Мөгайнетдинов белән 6 сәгатьлек сменага чыктылар. Сөйләшүләреннән аңлашылганча, инспекторларның күп вакыты исерек машина йөртүчеләр белән көрәшкә һәм һәлакәтләрне теркәүгә китә икән. Өстәвенә, административ кагыйдә бозучыларны ачыклыйсы, юл хәрәкәте иминлегенә контроль алып барасы бар.

– Ярый ла машина йөртүчеләр аңлый торган булса. Еш кына һәлакәтләрдә катнашучылар юл уртасында ук мөнәсәбәтләр ачыклый башлый, – ди ЮХИДИ системасында 7 ел стажы булган өлкән лейтенант Ринат Мөгайнетдинов. 10 минутлап вакыт уздымы-юкмы – беренче хәбәр дә килеп ирешә. Шәһәр үзәгендәге кибетләр янында ике җиңел машина юлны "бүлешә" алмаган. Бәхеткә, зыян күрүчеләр юк. ДПС инспекторлары урынга килеп җитү белән эшкә тотындылар. Берсе тормоз юлларын үлчи, икенчесе машина йөртүчеләрдән күрсәтмәләр ала. Документлар белән мәшәкатьләнә торгач, бер сәгать узып та китте.

Мәгълүматлардан күренгәнчә, районда машиналар саны арта тора, беренче кварталда гына да 2000гә якын транспорт чарасы теркәлгән. Машиналар арткан саен, һәлакәтләр дә арта, билгеле.

– Еш кына һәлакәтләр машина йөртүчеләрнең игътибарсызлыгы аркасында килеп чыга, – дип сүзгә кушыла Илназ Җиһаншин. – Кайбер машина йөртүчеләр юл билгеләренә бөтенләй игътибар бирми. Машина йөртү культурасы түбән.

Илназ бүлекнең иң яхшы юл инспекторы икән. Узган ел гына да лейтенат Илназ Җиһаншин 3 меңнән артык кагыйдә бозучыны тоткарлаган. Шуларның 150се – исерек көе руль артына утыручылар.

– Һөнәри бәйрәмебезне яхшы күрсәткечләр белән каршы алабыз, – ди бүлек начальнигы Рөстәм Гарипов. – Узган елгы нәтиҗәләр буенча, республика күләмендә беренче унлыкка кергән булсак, быелның I кварталында икенче урынга күтәрелдек.




ИЛНАЗ ҖИҺАНШИН ҺӘМ РИНАТ МӨГАЙНЕТДИНОВ ЧИРАТТАГЫ РЕЙД ВАКЫТЫНДА

Барлык күрсәткечләр буенча да негатив саннар киму ягында. Монда халык арасында үткәрелгән профилактик чараларның йогынтысын билгеләп үтми булмый. Личный состав һәм ветераннарыбыз бу юнәлештә актив эш алып бара. Ай саен юллардагы аварияләлек торышына анализ ясыйбыз. Юл-транспорт һәлакәтләрен китереп чыгаручы факторларны ачыклыйбыз. Мәсәлән, соңгы арада теркәлгән юл-транспорт һәлакәтләренең сәбәбе – исерек көе руль артына утыру, тизлекне арттыру, каршы як полосага чыгу. Агымдагы елның 6 ае эчендә кагыйдә бозучыларга карата 3895 беркетмә төзелде, 254 административ материал судка юлланды. Саннар уңай якка үзгәрде дип, тынычланып утырмыйбыз, әлбәттә. Һөнәри бәйрәм көнендә дә инспекторларыбыз постта, һәм юл кагыйдәләрен төгәл үтәү алар өчен иң зур бүләк булачак.

Зилия **ӘКСАНОВА**

# КӨН АРТЫННАН КӨН

ТАНСЫК!

## Ниһаять, яңгыр!

**Сишәмбе көнне районда явып үткән яңгырларга сөенмәгән кеше калмагандыр. Табигатьтә корылык куркынычы янаган эсселекне бастырыр, басуларга аз булса да файда булыр, дигән өмет авыл хуҗалыгыннан ерак торган шәһәрлеләр телендә дә еш яңгырый бу көннәрдә. Ә белгечләр бу хакта ничек уйлый?**

**Нургали Мусин, ТРның атказанган агрономы, хезмәт ветераны.**

–Нурлатта бу көнне 25-26 мм яңгыр яуды, бу айлык норманың яртысына якын. Ә туфракка үтү өчен 10 мм яңгыр да җитә, шуңа бу яңгыр бар тереклеккә дә файдалы булачак, дип уйлыйм. Шул исәптән бөртекле культуралар өчен дә. Дөрес, ул рекордлы уңыш вәгъдә итә алмый, анысы формалашкан инде. Ә менә бөртекләр тулышуга, орлыкларның массасын арттыруга булышачак.

Әлбәттә, азык культураларына–күпьеллык үләннәргә, суданка, кукурузга, чөгендер, бәрәңгегә ярдәме зур булачак. Бәрәңгенең, мәсәлән, нәкъ чәчәк атып килгән чагы хәзер.

**Фаил Ивандеев, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге начальнигы.**

–Яңгыр бер үк микъдарда булмаса да бөтен район буенча үтте. Биляр Озеро, Фома якларына аеруча кирәк иде, анда 49,8 мм яуды. Киекле, Андреевка якларында 20-25, Әлмәт кустында 25-30 мм яңгыр төште. Соңгысында әле алдагы көнне дә явым-төшем узган иде. Авыл хезмәтчәннәренең күңеленә өмет булып ятты инде ул яңгырлар. Районда бит зур мәйданнарда чөгендер игелә, кукуруз, бәрәңге дә бар, җәмәгать терлекләренә азыкны да мулдан әзерләү шарт. Күрелгән агротехник чараларның нәтиҗәлелеге дә күпмедер дәрәҗәдә дымга, яңгырга бәйле бит, һәм бар да уңайга булсын иде, дип тырышабыз.

**Ә Чулпаннан укучыбыз–Таһирҗан Әндәрҗанов яңгыр явуның сәбәбен үзенчә аңлатырга теләп шалтыратты.**

–Алдагы көнне генә әтиебез–85 яшьлек Мөнир Әндәрҗанов янына район башлыгы Равил Кузюров килеп, безнең гаиләгә кагылышлы проблеманы хәл итү чарасын күрергә ышандырып китте. Бик җылы итеп сөйләште, район хәлләре белән таныштырды,тик менә яңгырлар гына юк, дип борчылуын белдерде. Әтинең бик күңеле булып калды, шушы балаларның эшен уң ит, Ходаем, дип озаклап дога кылды. Мин могҗизага бик ышана торган кеше түгел, әмма болар арасында һичшиксез бәйләнеш бар, дип уйлыйм. Игелек кылган кеше моралына да ирешергә тиеш!

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА** сөйләште.



НЕФТЬЧЕ ЯШЬЛӘР ВЕТЕРАН ЯНЫНДА

## Ветеранга эш белән булышабыз

**"Ветеранга эшең белән булыш!" – "Нурлатнефть" идарәсенең яшьләр һәм профсоюз комитетлары әнә шул исемдәге акция үткәрделәр.**

Идарәнең яшь активистлары иң беренче булып идарә пенсионеры, Бөек Ватан сугышы ветераны, Аксубайда яшәүче Зиннәтулла Сөнгатулла улы Фәтхуллин янына юл алдылар. Аның шул арада гына су агызу җайланмасы эштән чыккан һәм яңгыр сулары торба буенча ага алмый икән.

Яшь ярдәмчеләрнең килүенә ветеран бик сөенде һәм эш процессы белән дәртләнеп җитәкчелек итте. Үзенең саллы яшенә дә карамастан, Зиннәтулла Сөнгатуллович шактый көр күңелле һәм җитез әле. Яшьләр аның физик активлыгына гына түгел, ә юмор хисенә дә соклandылар. Мондый "җитәкче" белән эшләү бик ипле барды. Су агызу торбасы бер дигән итеп төзәтелде, хәтта сынау да узды әле: өй түбәсеннән агызылган бер-ике чиләк су тиешенчә торба буйлап агып, түтәлләргә җәелде.

Шул көннәрдә "Нурлатнефть" идарәсе активистлары НГДУның тагы бер пенсионеры, Самара өлкәсенең Чаллы Башы районы Сиделькино авылында җәмәгате белән көн күрүче Бөек Ватан сугышы ветераны Михаил Михайлович Романов янына да барып кайтырга планлаштыралар.

**Марина КОРНИЛОВА,** идарәнең яшьләр лидеры

"ФРОНТТАН ХАТ" ПРОЕКТЫ

## "Гомергә яратачакмын..."

**Нурлаттан Зевакиннарның гаилә архивында фронт хатлары аерым урын алып тора. 73 ел дәверендә аларның 53е сакланган, ә үзләре шактый күп булган.**

Саргайган өчпочмаклыклар, кыр почтасы мөһере сугылган карточкалар әтиләре Михаил Зевакинның хатирәләре булып саклана, ул сугыштан исән-имин кайта алмаган. Дары исе сеңгән хатларда сугыш сулышы, окоплардагы мәшәкатьле көннәр, солдат йөрәгенең җылысы чагылган...

"Сөеклем Уля, мин сине яратам. Бары тик күзләрем йомылгач, йөрәгемне кан саугач, сулышым туктагач кына онытырмындыр...

Ул вакытта Мәскәү янында дәһшәтле һәм канкойгыч сугышлар бара. Туганнары һәм якыннарының йөрәкләрен яраламас өчен, элемтә взвод командиры Михаил Зевакин үзенең мәхәббәте турында яза, кечерәк кенә кәгазь кисәгенә шигъри юллар төшерә. Кайчагында ашыгып, кәгазь битен тезләренә куеп яза. Һәм һәр хаты: "Исән-сау..." дигән сүзләр белән тәгәлләнә. Хисләренең җаваплы, бернигә дә карамастан үзен көтүләрен тою фронтовикка көч һәм исән-сау кайтачагына өмет өсти. Әмма... Михаил Зевакинның гомере 26 яшендә өзелә. 1943 елның апрелендә аның корсак куышлыгы яралана, һәм июнь башында ул госпитальдә яраларыннан үлә. Фронтовикның хатыны Ульна Лаврентьевна 20 ел буе ирен көтә һәм аның исәнлегенә, кайчан да булса кайтып керәчәгенә ышанып яши. Чөнки Михаил бердәнбер улын да күрмәгән була бит әле, һәм хат саен аңа сәламен юллый, тизрәк үс, дошманны җиңәргә ярдәм итәрсең, дип яза. Әлеге хатларны фронтовикның тол хатыны гомере буе саклый. Иренең улларына Евгений дип исем кушуын сораува да карамастан һәм каенанасының үгетенә колак салып, Ульяна аңа Михаил дип исем куштыра. Михаил 1941 елның сентябрендә, сугыш башланып өч ай узгач дөньяга килә. Ә бераз үсә төшкәч, фронт хатларын еш укыштыра, укытучы булып эшләгәнлектән, батырлык дәресләрендә аларны укучыларга күрсәтә. Якын кешеләрен югалту ачысы бүген дә Михаил Зевакинның җанын әрнетә. Архивлар һәм музейлар аша ул әтисе җирләнгән урынны таба: ул Тверь өлкәсенең Осташков шәһәре, 13нче туганнар каберлеге.

Фронтовик Михаил Зевакинның иҗади сәләте улына да күчә. Район газетасы укучылары аның шигырьләре белән таныш инде. Михаил Михайловичның иҗат дәфтәре елдан-ел яңа рифмалар һәм әтисенә күрергә насыйп булмаган Бөек Җиңү юбилеена багышланган шигъри юллар белән тулылана тора.




Автор фотосы

**Маргарита ЛИТТА**

ХӘТЕР

## Урал кызы – асыл кош

**Биккол авылы үзенең хөрмәтле кешесе – Ирина Ананьевна Васильеваны соңгы юлга озатты. Авыл халкы, үзе укыткан балалар аны яратып, Ирина апа дип йөртә иде.**

Ул безнең төбәккә педагогия училищесын тәмамлап, Урал якларыннан килә. Хезмәт юлын Аксумла мәктәбендә башлап җибәрә. Безнең авылның күренекле егете Зыятдин – яшь белгеч – шул тирә авылларда терлек табибы булып эшләп йөри. Танышып китәләр, егет Ирина апага өйләнә һәм авылга алып кайта. Авыл халкы бу яшь кызның тырышлыгын, татар-мөселман тормышын үз итүен тиз күреп ала. Алар үз тормышларын коралар, бербер артлы дүрт бала дөньяга килә. Аларны үстереп, югары белем биреп, тормыш юлына бастыралар.

Ирина апа – Биккол авылының берничә буын балаларына рус телен өйрәтүче укытучы. Аның дәресләре үзенчәлекле була, башка укытучыларныкыннан аерылып тора иде. Ирина апа өчен "яхшы" яки "начар" укучы дигән төшенчә юк. Без аның каршында һәрберебез – үзенчә, кечкенә шәхес, ул безнең барыбызны да ярата, без дә аны яратабыз. Табигатьнең иң матур кочагында – Урал ягында үсеп, чын табигать баласы булганлыктан, бәлки шул туган якларын сагынгангадыр, һәр дәрестә безгә шул табигать турында сөйләргә вакыт таба. Урал табигатенең байлыгы, матурлыгы белән төрле балачак вакыйгалары аша таныштыра, ә без әкият тыңлаган кебек, рәхәтләнеп тыңлыйбыз, үзебезнең дә шул урманнарда җиләк җыясы, шул чишмәләрнең салкын суын эчәсебез килә кебек...

Ирина апа – безнең авылга язмыш бүләге, Урал тауларыннан очып килгән асыл кош, Урал тауларының бер асыл ташы булды. Ул Биккол җирен туган иле итеп, халкын үзенең туганнары күреп яшәде, аларга тел байлыгын гына түгел, табигать хәзинәләрен дә ачты. Аның җиңел кулы белән җыелган үләннәр тәнгә шифа, игелекле йөрәге җанга дәва бирде. Ирина апа безнең күңелләрдә мәңге шундый булып сакланыр!

Ирина апаны соңга юлга озатырга авыл халкы, күпләгән укучылары җыелган иде. Тик, нишләптер, 40 ел гомерен балалар укытуга багышлаган, зур хөрмәткә һәм ихтирамга лаек кешене соңгы юлга озатырга килүчеләр арасында мәгариф идарәсеннән дә, ветераннар оешмасыннан да (аңа 93 яшь иде) кеше күренмәде. Бу вәкилләр әйтәсе сүзне авылның имам-хатыйбы Рафаэль Гәрәев җиткерде.

**Гөлсирә ӘХМӘТШИНА,** Нурлат шәһәре.

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом, варианты. Т. 8-919-684-40-03.
*дом, ул. Мира. Т. 8-917-397-00-48.
*2-этажный дом, ж/д, все есть. Т. 8-937-600-48-07.
*дом по ул. М.Джалиля. Т. 8-927-049-87-79.
*1-комнатная квартира, 47 кв.м, ул. Нурлатская, 15, 4/5 этаж, индивидуальное отопление. Т. 8-927-468-36-53.
*дом. Т. 8-917-262-72-94.
*дом в с. Степное Мамыково, имеются гараж, баня, озеро, участок. Т.: 8-927-650-20-12, 8-937-188-05-48.
*комната в г.Самара, рядом с мед. университетом. Т. 8-927-032-23-03.
*дом, квартира. Т. 8-927-041-39-93.
*дом в с. Биляр-Озеро. Т. 8-927-425-10-16.
*3-комнатная квартира, ул. Советская, 195 (дача, гараж). Т. 8-927-243-65-08.
*дом с готовым бизнесом, мкр. Западный (Афганский), ул. Симбирская, 4, 5,5 млн.; участок в пос. Курмыш, без построек, свет, газ, вода есть, асфальтированная дорога, 150000 руб., торг. Т. 8-927-036-84-81.
*комната в общежитии. Т. 8-927-478-44-93.
*3-комнатная квартира, гараж, ул. Нефтяников. Т. 8-937-003-95-54.
*1-комнатная, 2-комнатная квартиры в центре. Т. 8-927-423-80-69 (после 17.00).
*дом, ж/д. Т. 8-927-676-25-75.
***2-комнатная квартира,** ул. Гиматдинова, 80, 1100 тыс. руб.; **2-комнатная квартира**, ул. Гагарина, 2, 860000 руб.; **2-комнатная квартира**, ул. Советская, 195, 1050000 руб. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.
*коммерческое помещение, ул. Нурлатская, 31, 1400 тыс. руб.; новый дом, ул. Юбилейная, 4 млн. руб., торг; недострой, ул. Ипподромная, 1050 тыс. руб.; дом жилой, ул. Кутузова, 1650 тыс. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.
*участок в Пушкине. Т. 8-917-265-47-54. П/с 16-16-03/014/2007-407.
*срочно кап.гараж с дачей по ул. Шашина, собственность, торг. Т. 8-927-871-55-07.
*1-комнатная квартира, центр. Т. 8-937-580-20-79.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-2109», 2004 г/в, темно-зеленый инжектор. Т.: 8-927-433-50-42, 8-927-441-86-56.
*«ВАЗ-21154», в хорошем состоянии, 2008 г/в. Т. 8-927-458-17-84.
*«Шевролет Лачетти», серебристый, седан, 2008 г/в. Т. 8-917-922-31-69.
*грузовой автомобиль «Фредлайнер» (2004 г/в) и прицеп «Шмитц» (2007 г/в), 1 млн. 700000 руб. Т. 8-927-036-84-81.
*«ВАЗ-2106», 2000 г/в, на ходу. Т. 8-937-611-82-91.
*«ВАЗ-2107», 2009 г/в. Т. 8-927-481-30-38.
*«Ока», в хорошем состоянии. Т.: 8-927-405-12-01, 8-927-404-54-32.
*«ВАЗ-2107», 2004 г/в. Т. 8-927-402-16-92.
*«МАЗ» (самосвал), 2014 г/в, 20 т. Т. 8-987-286-70-01.
*цельнометаллическая «ГАЗель», 2002 г/в. Т. 8-937-589-52-95.
*«ВАЗ-21102», 2000 г/в. Т. 8-927-483-51-46.
*«ВАЗ-2107», 2007 г/в. Т. 8-917-265-70-19.
*«Шевроле Нива-2123», 2011 г/в, цвет черно-синий металлик, один хозян. Т. 8-917-391-08-76.
*«ВАЗ-2107», 2007 г/в, 60 тыс.руб. Торг. Т. 8-929-722-38-68.

## ДРУГОЕ

*ШИКӘР КОМЫ-2230, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.
*куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.
*бычки (молодняк) от 2 до 5 месяцев. Т. 8-927-870-58-98.
*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*доски осина, сосна, брусья 6 метров. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.
*ПГС, песок, глина, перегной, грунт от 3 т. Т. 8-927-424-02-83.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-937-617-11-21.
*ПГС, бут, песок. Т.: 8-927-675-54-96, 4-37-14.
*ручной листогиб фирмы «Тарсо», для изготовления доборных элементов. Т. 8-917-856-27-28.
*ПГС, песок, бут, цемент, керамзит, щебень. Т. 8-927-401-51-91.
*кровать подростковая (с ящиками), кроватка (качалка), коляска-трость, холодильник «Свияга» (однокамерный). Т. 8-927-437-47-92.
*корова. Т. 8-917-248-86-77.
*спальный гарнитур, мягкая мебель. Цена при осмотре. Т. 8-927-406-50-51.
*газобетон 10х25х60, 2000 руб. куб.м, кольца 1 м 20 см на 5 м, 10 тыс. руб., ПГС, песок. Услуги манипулятора. Т. 8-927-405-76-08.
*деревянная койка. Т. 8-927-415-75-82.
*пластиковое окно, б/у, размер 150х80. Т. 8-927-422-32-67.
*куры-молодки, утята, мулярды. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.
*Камышлинский инкубатор реализует подрощенных бройлеров. Т.: 8-937-620-80-30, 4-35-47 (Румия).
*телка, 1 мес. Т. 8-927-414-07-36.
*бычок на мясо (частями, 265 руб/кг), баранина ( 275 руб/кг). Т. 8-927-459-13-70.
*канарейки. Т. 8-917-932-75-06.
*телята от недели до 3 месяцев. Т. 8-927-460-96-30.
*поросята. Т. 4-32-07.
*семена – костер, люцерна. Т. 8-927-470-39-02.
*сено, солома, телята мясной породы. Доставка. Т.: 8-909-345-99-77, 8-937-343-80-22.
*картошка. Т. 8-937-581-93-57.
*диван. Т. 8-9270-35-72-68.
*дрова. Т. 8-927-414-61-34.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-937-617-11-21.
*сруб бани. Т. 8-917-262-72-94.
*сруб бани. Т. 8-927-470-18-04, Сергей.
*сруб бани под ваш размер и комплект досок к бани. Т. 8-927-419-57-81.

## РАЗНОЕ

*Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.
*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.
*услуги сварщика (любой сложности). Т. 8-937-004-40-78.
*ремонт пластиковых окон, москитных сеток. Т. 8-927-249-54-24.
*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.
*установка окон, дверей, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.
*фундаментные работы любой сложности. Т. 8-937-280-67-25.
*услуги электрика. Т. 8-937-614-70-15.
*грузоперевозки, «ГАЗель», 4 м, 16 куб. Т. 8-927-247-12-61.
*копаем, заливаем фундаменты. Услуги каменщика. Т. 8-937-294-65-52.
*копаем, чистим колодцы, выполняем земляные работы. Т. 8-937-776-79-45.
*копаем, чистим колодцы. Т.: 8-986-711-25-32, 8-929-723-88-60.
*ремонт квартир. Т. 8-927-446-99-98.
*ремонт, настройка компьютеров, Wi-Fi, Интернета. Выезд. Т. 8-937-0051-451.
*штукатурка, кровля, вагонка, бетонные работы. Т. 8-917-865-30-35.
*быстро, качественно плитка, мозаика, все виды отделочных работ. Т. 8-987-971-15-18 (Геннадий).
*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.
*отопление, водопровод, сантехника, недорого. Т. 8-937-772-43-81.
*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.
* Обшивка домов, кровля и другие строительные работы. Т. 8-9274-222-633.
* Утерянный техпаспорт и водительское удостоверение на имя Айрата Вазировича Халиуллина прошу вернуть за вознаграждение. Т. 8-9274-222-633.
***ремонт, настройка компьютеров, ноутбуков, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-0051-451.**
*ищу работу домработницы. Т. 8-917-932-75-06.
*ежедневно Нурлат-Самара, автовокзал, глазные клиники. Т. 8-927-031-29-33.
*услуги сиделки. Т. 8-927-421-18-10.
*шпаклевка, поклейка обоев, недорого. Т. 8-929-728-61-14.

## ТРЕБУЕТСЯ

*электромонтер. Т. 8-917-298-19-24.
*газорезчики, грузчики. Т. 8-927-438-54-95, 8-927-428-83-88.
*в ООО «Здоровье» пекари, операторы хлебопекарных печей, разнорабочие. Т. 8-927-417-62-73.
*Нурлатскому предприятию буровых работ ООО «Бурение» помощники бурильщиков эксплуатационного и разведочного бурения скважин на нефть и газ; слесари по обслуживанию буровых; электромонтеры по обслуживанию буровых; машинисты буровых установок на нефть и газ. По вопросам трудоустройства обращаться в отдел кадров по адресу: г.Нурлат, ул. Советская, 130, тел. 92-2-60.
*продавец. Т. 8-937-777-00-08.
*в ТСЦ «Мастерстан» продавец. Т.: 8-929-722-03-51, 8-937-290-95-11.
*электромонтер, слесарь-ремонтник, водитель. Т. 2-05-74.

## КУПЛЮ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.
*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.
*баллоны кислородные, углекислотные. Т. 8-987-292-01-10. ООО «ГК «Втормет».
*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.
*б/у ж/б опоры. Т. 8-937-584-76-32.
*пух гусиный, утиный, старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.
*КРС. Т. 8-927-481-30-38.
*б/у ж/б опоры. Т. 8-937-584-76-32.

## СДАЮТСЯ

*в аренду помещения в новом торговом центре с. Челно-Вершины, от 10 до 700 кв.м. Т. 8-937-645-78-42.
*квартира посуточно, командировочным. Т. 8-927-456-05-69.
*квартира порядочным. Предоплата. Т. 8-927-041-77-68.

## СНИМУ

*2-комнатную квартиру. Т. 8-927-432-25-63.

## ХУШЛАШУ СҮЗЕ



**Ислам Усман улы ГЫЙЛӘҖЕВ**

Нурлат районы Илсам Усман улы Гыйләҗев белән хушлашты. Ул 1927 елның 15 октябрендә ТАССРның Октябрь районы Биккол авылында туа. Хезмәт эшчәнлеген сугыш елларында ТАССРның Октябрь районы, "Заря" колхозында бригадир булып башлый. 1944-1955 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт уза. Армиядән кайткач, Ислам Усманович гомерен туган төбәгенә хезмәткә багышлый, идеология өлкәсендә һөнәри юлның төрле этапларын уза, җитәкче постлар биләп тора. 1971 елда Казан дәүләт университетын тәмамлап, югары белем ала.

Ислам Усманович кайда гына эшләмәсен – КПССның Октябрь райкомындамы, "Красный ударник" колхозының партком секретаре вазифасындамы, ТАССРның Октябрь районы Госстрахында, ДОСААФның Октябрь район комитетында, "Знание" җәмгыятенең Октябрь район оешмасында яки башка урыннардамы – һәркайда ул үзен җаваплы, компетентлы һәм тәртипле кеше итеп күрсәтте. Ул һәрвакыт җәмәгать эшчәнлеге белән шөгыльләнде, актив гражданлык позициясендә иде. Аны белүчеләрнең барысы да Ислам Усмановичның һәрчакта да дөрес карар таба белүен билгеләп үтәләр. Ул теләсә нинди вазифада һәм теләсә нинди ситуациядә дә тыйнак, тотнаклы һәм гадел булып кала белде.

Ислам Усмановичның гаиләсе, туганнары, якыннарының тирән кайгыларын уртаклашабыз. Аның турында хатирәләр күңелләрдә мәңге сакланачак.

**Р.Ә.Кузюров, Ф.Р.Ногманова, Ә.К.Габдуллин, О.А.Микушкин, И.С.Сафиуллин, Е.К.Савинов, Р.И.Садретдинова**

**12+ "ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә**

**6 ИЮЛЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**8 ИЮЛЬ**
"Нурлат хәбәрләре",
"Татнефть" хәбәрләре.

**10 ИЮЛЬ**
**"Нурлат хәбәрләре".**
**"Сиңа дигән җырым"**, музыкаль тапшыру

Программалар **19** сәгатьтә башлана. **7, 9, 11 июльдә** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

**ПЕНОИЗОЛ. УТЕПЛЯЕМ СТЕНЫ, ПОТОЛКИ**
**ЖИДКИМ ПЕНОПЛАСТОМ**
**8-937-600-33-02,**

**ПРОДАЕТСЯ**
ОСП-ПЛИТЫ,
ГИПСОКАРТОН.
**Т.: 2-04-68,**
**8-927-413-69-82.**

**НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ**
*любой сложности.*
**8-9600-33-77-55.**

**ПАМЯТНИКИ (мрамор, гранит). Фото на граните.**
**Доставка, установка.**
**Ул. Ленинградская, 14.**
**8-987-420-05-97.**

**«УДАЧА»**
**Продолжается набор групп для отдыха на Черном море выездом на поезде 5 и 15 августа.**
**Т. 8-927-417-17-10.**

**М-н «КОЛЬЦО»**
- цемент «Жигулевский» 50кг;
- ТЕПЛИЦЫ;
- газобетон;
- доломитовый блок;
- кирпич в ассортименте;
- сухие смеси;
- кольца для колодца и канализации.

**г.Нурлат, мкр. Западный («Афганский»), напротив АЗС-Татнефть.**
**8(84345)2 80-57,**
**8-9276-755-091.**

**Закупаем лом**
**черный**
**3А - 7000 руб./тн**
**5А - 6000 руб./тн**
**12А - 5500 руб./тн**
**цветной**
**медь - 255 руб./кг**
**алюминий - 55 руб./кг**
**АКБ - 35 руб./кг**
**Территория бывшего вещевого рынка.**
**Т.:8-917-932-01-50,**
**8-927-444-70-80.**

**УСЛУГИ АВТОКРАНА, 25 т., вылет стрелы 21 м.**
**8-927-444-70-80.**

**«Доктор Оптика» - ваш новый имидж!**
*Цветные контактные линзы - чудесное преображение ваших глаз. Широкая палитра цветов от известных производителей!*
**Салон «Доктор Оптика»**
**г. Нурлат, ул. Советская, 120,**
**т.: 2-17-88, 8-927-427-79-27,**
**ул. Гиматдинова, 81,**
**т.: 2-91-99, 8-937-610-69-30,**
**ТЦ «Радуга» (2 этаж),**
**т. 8-937-613-99-88,**
**ТЦ «Шифа», ул. Кариева, 1Д.**
Лиц. №16-01-000675 от 13.12.2007г., выд. Фед.службой по надзору в сфере здравоохранения и соц.развития.
**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.**

**БАВАРСКИЕ ОКНА**
Тепло и уют Вашего дома.



- Пластиковые окна, лоджии, двери;
- Металлические и межкомнатные двери;
- Арки
- Горизонтальные и вертикальные жалюзи;
- Автоматические ворота;
- ОСП, гипсокартон;
- Теплицы
- Натяжные потолки

СКИДКИ – 1000 руб. на КАЖДОЕ изделие *
**МОСКИТНАЯ СЕТКА В ПОДАРОК**
Кредит**
Доставка и выезд инженера по замеру по г.Нурлат осуществляется - БЕСПЛАТНО!
Наш адрес: г.Нурлат ул.Советская, 92.
Тел.89370085308, 89274136982, 2-04-68



*скидки действуют на пластиковые изделия в период с 01.07.15 по 31.07.15 г. Условия у продавцов. Организатор: ИП Чванова Л.П.
**кредит предоставляется АО «ОТП Банк».
Реклама

**Магазин «РОЗАЛИЯ»**
*Большое поступление мебели производства Белоруссии, Калининграда, «Шатура» и т.д. Кредит, рассрочка (предоставляют ООО «Хоум Кредит энд Финанс Банк», ООО «Русфинанс Банк»).*
**Ул. Хамадеева, 15А.**
**2-37-04.**

**«ДОБРАЯ ПОДУШКА» - реставрация подушек. Увезем, привезем по городу бесплатно. Работаем с 9.00 до 18.00 без выходных.**
**8-927-436-01-96, 8-937-296-29-53.**

**МАГАЗИН «СПОРТТОВАРЫ»**
**- ТРЕНАЖЕРЫ**
**- САМОКАТЫ**
**- ВЕЛОСИПЕДЫ**
**- РОЛИКИ**
**- МЯЧИ**
**- ФИТНЕС**
**- КОНЬКИ**
**- БОКС**
**И ДР. СПОРТИВНЫЙ ИНВЕНТАРЬ.**
**Мини-рынок (мясокомбинат), центральный вход.**

**ОО «Гарантия качества» предлагает ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА европейского качества по доступной цене заводского производства. Рассрочка без %, без участия банка. Т. 8-927-405-53-52.**

## Кайгы уртаклашабыз

Авыл хуҗалыгы һәм азык- төлек идарәсе коллективы, идарәнең элеккеге баш юристы **Ислам Усман улы ГЫЙЛӘҖЕВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, аның туганнары һәм якыннарының тирән кайгыларын уртаклаша.

